**16:39:080301:679 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү**

1. 16:39:080301:679 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча **халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итәбез.**

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**
- Мусабай-Завод авыл җирлегенең гамәлдәге Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләреннән выкопировка.

**3. Проект буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары:**
Халык тыңлаулары 2026 елның 3 июленнән 2026 елның 17 июленә кадәр үткәрелә.
Халык тыңлауларын үткәрү процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- халык тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Халык тыңлауларында катнашучылар даирәсе:**
- Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Мусабай-Завод авыл җирлеге чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Чикләрендә халык тыңлаулары уздырыла торган территория:** Мусабай-Завод авыл җирлеге.

**6. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**
- 10.07.2026, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 33А йорты, авыл мәдәнит йорты янында;
- 10.07.2026, Таш-Кичү авылы, Үзәк ур., 39, кибет;
- 10.07.2026, Кызыл-Байрак авылы, Үзәк ур., 37А йорты, тукталыш павильоны янында.

**7. Проект экспозициясен үткәрү сроклары:** 2026 елның 10 июленнән 2026 елның 17 июленә кадәр чорда.

**8. Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**дүшәмбе-җомга 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр.

**9. Халык тыңлауларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:**
2026 елның 10 июленнән 2026 елның 17 июленә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык тыңлауларында катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:
- халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язма яки телдән;

- язма рәвештә яки электрон документ формасында халык тыңлауларын оештыручы адресына: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 101 каб.;

- авыл мәдәният йортында халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 33 А йорты

**10. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:** 2026 елның 17 июлендә 16:00 сәгатьтә мәктәп бинасында, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 27.

**11. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар** 2026 елның 10 июленнән Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «Документлар/иҗтимагый һәм халык тыңлаулары» бүлегендә урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрнамәне** «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Мусабай-Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 15AE296FD75F49CE6CBF538F55CA0DD1
Владелец: Маняпов Линар Нурисламович
Действителен с 11.11.2025 до 04.02.2027

Л.Н. Маняпов